## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**23 ноябрь 2022 ел** **№1**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Беренче Май авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Уставы нигезендә 2022 елның 23 ноябрендә түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча гаражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде:

«Сез, 2023 елда Урманай авыл җирлеге Беренче Май бистәсе торак пункты территориясендә Беренче Төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, кендезге уку формасында укучы студентлардан, гаилә әгъзасы мобилизацияләнгән һәм махсус хәрби операциягә җибәрелгән гаиләләрдән тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү (бүләк һәм сувенир продукция сатып алу, «Яңа ел», «Җиңү кене», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне " бәйрәм чараларын үткәрү хезмәтләре күрсәтү»);
- Халыкны су белән тәэмин итүне, ташландык суларны агызуны оештыру (су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау һәм карап тоту, шартнамә буенча эшләр өчен түләү, материаллар, җиһазлар сатып алу, авария хәлләрен бетерү, торбаларны алыштыру, су чыганакларын санитар саклау зоналарын тезекләндерү, ЗСО проектларын әзерләү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, эчә торган суга биохимик һәм бактериологик анализ үткәрү);
- Беренче Май бистәсе территориясен төзекләндерүне оештыру (территорияне кипкән агачлардан һәм куаклардан чистарту, территорияне механикалаштырылган чабу буенча хезмәтләр өчен түләү, трактористка механикалаштырылган кар чистарту буенча хезмәт ечен түләү, юлларны кардан чистарту буенча чит оешмалар хезмәтләре өчен шартнамә буенча эшләр өчен түләү, МТЗ-82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары һәм запчастьләр сатып алу, территорияне санитар чистарту хезмәте күрсәтү).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия 141 граждан җыенында катнашучы теркәлгән, халык җыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны 74.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен 74, «КАРШЫ» позициясе өчен 0 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Беренче Май торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – гамәлдә (дөрес) дип танырга.
2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга:

«Сез, 2023 елда Урманай авыл җирлеге Беренче Май бистәсе торак пункты территориясендә Беренче Төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, кендезге уку формасында укучы студентлардан, гаилә әгъзасы мобилизацияләнгән һәм махсус хәрби операциягә җибәрелгән гаиләләрдән тыш, яшәү

урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү (бүләк һәм сувенир продукция сатып алу, «Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне " бәйрәм чараларын үткәрү хезмәтләре күрсәтү»);

- Халыкны су белән тәэмин итүне, ташландык суларны агызуны оештыру (су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау һәм карап тоту, шартнамә буенча эшләр өчен түләү, материаллар, җиһазлар сатып алу, авария хәлләрен бетерү, торбаларны алыштыру, су чыганакларын санитар саклау зоналарын тезеклəндерү, ЗСО проектларын әзерләү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, эчә торган суга биохимик һәм бактериологик анализ үткәрү);

- Беренче Май бистәсе территориясен тезеклəндерүне оештыру (территорияне кипкән агачлардан һәм куаклардан чистарту, территорияне механикалаштырылган чабу буенча хезмәтләр өчен түләү, трактористка механикалаштырылган кар чистарту буенча хезмәт өчен түләү, юлларны кардан чистарту буенча чит оешмалар хезмәтләре өчен шартнамә буенча эшләр өчен түләү, МТЗ-82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары һәм запчастьләр сатып алу, территорияне санитар чистарту хезмәте күрсәтү).

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Урманай авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakayevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Урманай авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Урманай авыл җирлеге башлыгы

Э.Р.Абдуллина